**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«23» июнь 2021 ел** **№ 25**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 101 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 30.12.2020 ел, № 494-ФЗ Федераль законның 1 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 101 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 12 статьяда:

өченче абзацны түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга, «әлеге статьяның дүртенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш.»;

түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзацны өстәргә:

“Җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителү сәбәпле, җәмәгатьчелек фикер алышулары яки гавами тыңлаулар территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин, аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән булса.»;

дүртенче, бишенче һәм алтынчы абзацларны бишенче, алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга.

3) 13 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче ур., 9;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Гагарин ур., 38, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга. https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы Рәисе А.Г.Җиһаншин**